| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.02.2024 ел Баулы шәһәре №10

2021 елның 30 июлендәге 139 номерлы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган, җир кишәрлеген алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 438-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 430-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1.2021 елның 30 июлендәге 139 номерлы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган, җир кишәрлеген алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 31 мартындагы 85 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәреш кертергә:

2 бүлектә «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты»:

2.8. бүлекчәсендә «Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге»:

2.8.3.1. пунктының 3) пунктчасының ж) абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) җир асты байлыкларыннан файдалану, линия объектларын, аларның аерылгысыз технологик өлешләрен, гидротехник корылмаларын, шулай ук су саклагычларын, башка ясалма су объектларын төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү максатларында барлыкка килә торган җир кишәрлегеннән тыш, аның чикләре территориаль зоналар, урманчылыклар чикләрен кисеп үтә торган җир кишәрлеге булдыру

рөхсәт ителми. Җир кишәрлекләренең территориаль зоналар чикләре белән киселешен ачыклаганда (чикләре әлеге пунктка ярашлы рәвештә Территориаль зоналар чикләрен кисеп чыгарга мөмкин булган җир кишәрлекләреннән тыш), урманчылыкларның мондый киселешен бетерү Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла. Әгәр башкасы федераль закон белән билгеләнмәгән булса, җир кишәрлеге барлыкка килү өчен җир кишәрлекләренең чикләре белән территорияләрне кулланунның аерым шартлары булган зоналар чикләре, иҗтимагый сервитут билгеләнгән территорияләр чикләре, мәдәни мирас объектлары территорияләре, аеруча саклана торган табигый территорияләр, махсус икътисади зоналар, аучылык җирләре, тиз үсеш территорияләре, Россия Федерациясендә территориаль үсеш зоналары, уен зоналарында, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләр, Байкал табигый территориясен һәм аның экологик зоналарын резервлау турында Карар кабул ителгән территориядә киселешнең булуы киртә булып тормый;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров